ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**31.01.2018**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 177**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күп фатирлы йортлар исемлеген раслау турында» 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы карарына, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының күп фатирлы йортларын авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану турында» 2009 елның 31 декабрендәге 2993 номерлы карарына үзгәрешләр кертү, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре, Гоголь урамы, 35 йорт адресы буенча җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларын тартып алу турында» 2015 елның 20 ноябрендәге 2439 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы Арбитраж судының 27.06.2016 ел, №А65-3803/2016 һәм 28.03.2017 ел, №А65-28422/2016 карарларын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күп фатирлы йортлары исемлеген раслау турында» 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы карары кушымтасына «Зеленодольск шәһәре, Гоголь, 35 нче йорт» 36 пунктны төшереп калдырып үзгәрешләр кертергә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының күп фатирлы йортларын авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану турында» гы 2009 елның 31 декабрендәге 2993 номерлы карары кушымтасына «Зеленодольск шәһәре, Гоголь, 35 нче йорт» 38 пунктны төшереп калдырып үзгәрешләр кертергә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре, Гоголь урамы, 35 йорт адресы буенча җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларын тартып алу турында» 2015 елның 20 ноябрендәге 2439 номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы органга;
- «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты » МКУ;
- торак урыннар милекчеләренә.

5. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга һәм Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең авария хәлендәге торактан гражданнарны күчерү программасын гамәлгә ашыру буенча урынбасары О.А.Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин